# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында" Татарстан Республикасы Законына һәм "Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында" Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында" 2008 елның 22 ноябрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасындагы II кисәгенең 6 бүлегендәге 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле яңа җиденче абзац өстәргә:

"территория префекты;";

2) җиденче – тугызынчы абзацларны тиешенчә сигезенче – унынчы абзацлар дип санарга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында" 2008 елның 26 декабрендәге 135-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

2 статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (V өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

"шәһәр округы башкарма комитетының территория префекты;";

2) сигезенче – унберенче абзацларны тиешенчә тугызынчы – уникенче абзацлар дип санарга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р. Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 24 сентябре
№ 62-ТРЗ